Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының
Татар Тау Иле авыл җирлеге Советы

Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

19 август, 2026 ел № 6

Татар тау Иле авылы

Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында 2017 елның 21 августындагы 71/71 номерлы нигезләмә (2017 елның 12 декабрендәге 83/29 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 95/9 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 126 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 59 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 66 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Татар Тау Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасында «аз катлы күп фатирлы торак төзелеше» (ОД) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Татар Тау Иле авыл җирлеге, Татар Тау Иле авылы адресы буенча урнашкан 1000 кв.м. мәйданлы, кадастр номеры 16:33:150102:410 булган җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлегенең гавами тыңлауларны оештыручыга - башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 4 сентябреннән дә соңга

калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районының
Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Габдрахманов

СОВЕТ ТАТАРСКО-ХОДЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ